ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты структурасына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Эшләр идарәсенең финанс бүлеген бетерергә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Финанс бүлеген оештырырга.

3. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты структурасын үзгәртү һәм штат санын оптимальләштерү турында» 2010 елның 22 октябрендәге 1205-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карарына (2013 елның 17 декабрендәге 3233-IV ДС номерлы, 2014 елның 23 октябрендәге 42-V ДС номерлы, 2016 елның 4 мартындагы 1104-V ДС номерлы, 2019 елның 16 октябрендәге 97-VI ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән), 1 нче кушымтаны әлеге карарга кушымтада каралган редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты структурасына әлеге карар белән кертелгән үзгәрешләр нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының штат расписаниесенә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Административ регламентына үзгәрешләр әзерләргә һәм аларны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе раславына кертергә, шулай ук законнар нигезендә кирәк булган оештыру-штат чаралары уздырырга тиеш.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ / АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2020 елның 17 апреле
№ 364-VI ДС

Татарстан Республикасы Дәүләт
Советы Президиумының
2020 елның 17 апрелендәге
364-VI ДС номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты
структурасы

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты түбәндәге структур бүлекчәләрдән тора:

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Секретариаты**, аналитика бүлеген дә кертеп;

**Оештыру идарәсе**, аның составына түбәндәгеләр керә:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге,

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге,

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге,

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты,

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге,

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге,

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге,

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге,

Татарстан Республикасы Дәүләт Советында фракцияләр эшчәнлеген тәэмин итү һәм оештыру эшләре бүлеге,

мәгълүмат-методика бүлеге;

**Хокук идарәсе,** аның составына түбәндәгеләр керә:

конституциячел законнар бүлеге,

граждан законнары бүлеге,

социаль законнар бүлеге,

законнар мониторингы һәм коррупциягә каршы экспертиза секторы;

**Эшләр идарәсе,** аның составына түбәндәгеләр керә:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эшчәнлеген мәгълүмати-технологик тәэмин итү бүлеге, күбәйтү-ишәйтү бүлекчәсен дә кертеп,

дәүләт сатып алулары секторы,

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы чараларына хезмәт күрсәтү һәм аның биналарын карап тоту бүлекчәсе, җитештерү-техник хезмәтне дә кертеп;

**Документлар белән тәэмин итү идарәсе**, аның составына түбәндәгеләр керә:

контроль һәм эш башкару бүлеге,

беркетмә бүлеге,

Татарстан Республикасы законнары һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советының норматив-хокукый документлары текстларын тәрҗемә итү һәм тәңгәлләштерү бүлеге,

редакцион-лингвистик экспертиза бүлеге;

**Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге;**

**Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү бүлеге;**

**Финанс бүлеге;**

**Матбугат хезмәте;**

**Яшеренлек режимын тәэмин итү һәм гражданнар оборонасы секторы.**